ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 гыйнвар 2018 ел № 315

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә «Россия гражданнарына – һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак» илкүләм проектын тормышка ашыруны тәэмин итү максатында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елнын 17 декабрендәге 1050 нче Карары белән расланган 2015-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләренең 11 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү Кагыйдәләренең 10 пунктына, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2018 елның беренче ярты еллыгына Россия Федерациясе буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы һәм 2018 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2017 елның 20 декабрендәге 1691/пр санлы Боерыгына туры китереп

К А Р А Р  Б И Р ӘМ:

1. Яшь гаиләләр өчен торак сатып алуга яки шәхси торак йорт төзүгә социаль түләү күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2018 елның беренче кварталына 37 378 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Р.Ә. Абдуллин